УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадалары, шулай ук исемлеге Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган мәктәп укучылары олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләк алучыларыннан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2010 елның 21 декабрендәге ПУ-835 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы биргән тәкъдимне карап тикшергәннән соң, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләре көндезге уку бүлекләренең укучыларның бөтенроссия һәм халыкара олимпиадалары, шулай ук исемлеге Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган мәктәп укучылары олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләк алучыларыннан булган студентлары өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләрен билгеләү турында» 2018 елның 30 августындагы ПУ-608 номерлы Указына, 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 47 пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«47) Софронова Сардаана Сергеевнага – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ студентына.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел,13 октябрь
№ ПУ-727